## Милли мәгариф: бүгенге торышы һәм үсеш перспективалары

*Әгәр дә милләтне көчле итеп, бөек итеп күрәсең*
*килә икән, иң беренче булып аның көчен таны,*
*шул милләтнең баласы булуың белән горурлан.*
***Туфан Миңнуллин***

Бүгенге көндә милли мәгарифкә республика күләмендә зур игътибар бирелә. Яшь буынга туган телне, әдәбиятны, тарихны, мәдәниятне өйрәтү иң әһәмиятле бурычлардан санала. Шуңа күрә дә 2021 нче ел Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип аталды.

**Балалар бакчаларында милли мәгариф**

Балалар бакчасы-мәгариф системасында беренче баскыч. Шуңа күрә балалар бакчасының төп бурычларыннан берсе —балаларда дөрес сөйләм телен формалаштыру. Балалар бакчаларында туган телне өйрәтү федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә, укыту-методик комплектын кулланып гамәлгә ашырыла.

Буа районында 39 балалар бакчасы эшли. Шуларның 10 сы шәһәрдә (1 татар балалар бакчасы, 9 бакчада рус һәм татар телләрен өйрәнәләр) . 29 балалар бакчасы авылларда урнашкан. Шуларның 17се татар, 3се рус, 9ы чуваш балалар бакчасы. Аларда барлыгы 383 бала тәрбияләнә.

Татар телен өйрәтү буенча тәрбиячеләр балалар бакчаларында өстәмә белем бирү хезмәтләре алып баралар. Балалар рус һәм татар төркемнәренә бүленә. Рус телле балаларның татар телен үзләштерү 79,2%, ә татар балаларының татар телен үзләштерү 88% тәшкил итә. Район буенча барлыгы 1643 бала шуларның 834 е татар милләтеннән (50,8 %). 416 сы тәрбияне туган телләрендә алалар (49,8%).

Шәһәр һәм "Миләшкәй" балалар бакчаларында штат расписаниесендә татар телен өйрәтү буенча тәрбиячеләр бар. Тәрбиячеләр ике дәүләт телендә шөгыльләр алып баралар. Татар телен өйрәтү ике яшьтән оештырыла. Балаларга туган телдә белем бирү сыйфатын яхшырту өчен барлык юнәлешләр буенча Хазратова Ф.В. “Туган телдә сөйләшәбез” укыту-методик комплектлары кулланыла. Дәресләрдә, төрле чараларда һәм конкурсларда

тәрбиячеләрбалаларның сөйләм телен үстерү һәм белем дәрәҗәсен арттыру өстендә эшлиләр.

Татар телен өйрәтү буенча тәрбиячеләр, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, билгеләнгән максатларга һәм куелган бурычларга карап, төрле педагогик, технологик методлар кулланалар. Белем бирү эшчәнлеге индивидуаль формада һәм төркемдә алып барыла. Балалар туган телдә сөйләшәләр, башкаларны тыңлыйлар һәм бер-берсе белән аралашалар. Татар телен өйрәтү буенча тәрбиячеләр үзләренең белем бирү эшчәнлеген уеннар, шигырьләр, табышмаклар, биюләр, җырлар кебек ысуллар һәм алымнар ярдәмендә тормышка ашыралар.

Татар телен өйрәтү буенча тәрбиячеләр әти- әниләр белән тыгыз элемтәдә эшлиләр. "Баланы туган тел һәм халык иҗатын кулланып тәрбияләү", "Балалар белән татарча сөйләшәбез" кебек темаларга әти-әниләр өчен консультацияләр үткәрелә. Халык- ара туган тел көненә багышланган чараларда һәм башка бәйгеләрдә әти –әниләр актив катнашалар.

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү-иң катлаулы методик бурычларның берсе. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтү аша тәрбиячеләр балаларда туган якка, табигатькә мәхәббәт һәм аңа сакчыл караш тәрбияли. Кече Ватаныбызның үткәненә карата горурлык һәм хөрмәт тәрбияли, патриотик хисләр уята. Кызыклы тарихи вакыйгалары, мәдәнияте, көнкүреше һәм бәйрәмнәре белән таныштыра. Моның өчен алар авторлык инновацион программаларын кулланалар. Слайдта күрәсез.

Балалар бакчаларына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министырлыгы тарафыннан яңа уеннар кайтты. Тәрбиячеләр аларны татар телен өйрәтүдә актив кулланалар.

Буа муниципаль районы мәктәпләрендә туган телне өйрәнү юнәлешендә шактый эш башкарыла. Районның милли мәгариф өлкәсендә “Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы” Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, укучыларның белемнәрен камилләштерү, туган телне һәм татар телен өйрәнүгә кызыксыну һәм

мәхәббәт тәрбияләү, методик әсбаплар һәм дәреслекләр белән тәэмин итү, милли мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын укытуның материаль базасын ныгыту буенча системалы эш алып барыла.

Яңа уку елында  милли мәгариф эшен камилләштерү буенча “юл карталарын” гамәлгә ашыру бурычы куелды.

Әлеге программа түбәндәге максатларын сез әлеге слайдларда күрәсез.

Буа муниципаль районының мәгариф учреждениеләре челтәренә 32 мәктәп һәм 9 башлангыч мәктәп керә, шуларның 18е - татар телендә белем бирүче  мәктәпләр.

Районда 4669 укучы. Шуларның  2848 е татар, 762 се рус, 1059 ы башка милләттән.Алар татар, рус, чуваш һәм башка милләт балалары.  817 укучы татар телендә белем бирүче мәктәптә, 3225 укучы рус телендә белем бирүче, 627 укучы чуваш телендә белем бирүче мәктәптә укыйлар. Ата-аналарның гаризасы нигезендә укучыларның 6% ы туган тел буларак рус телен, 82 % ы татар телен, 12 % ы чуваш телен өйрәнә.

М. Вахитов исемендәге гимназия шәһәр үзәгендәге татар мәктәбе булып исәпләнә. Анда 319 укучы белем ала. Шәһәр үзәгендәге калган 5 мәктәптә 2789 укучы белем ала һәм тәрбияләнә. Шуларның 1639 ы – татар милләтеннән (57%) , әмма 262 укучы гына белемне туган (татар) телендә ала һәм тәрбияләнә.  Бу күрсәткеч Буа шәһәре өчен бик түбән. Бу турыда Марат Готович ассызыклап әйтте. Укучыларның туган (татар) телендә белем алуын арттыру максатыннан киләсе уку елында барлык шәһәр мәктәпләрендә дә татар сыйныфлары ачу таләп ителә.

Татар балаларының  туган телдә укыту күрсәткечләре 29% тәшкил итә, бу былтыргы ел белән чагыштырганда 5,38% ка артыграк, ләкин бу аз!

2020 нче елның декабрь аенда 1-4 нче сыйныфлар өчен барлык татар мәктәпләре белән татар төркемнәре өчен 822 экземпляр татар теле дәреслеге кайтарылды. (Аторы Шакурова (107,636 мең). 2021-2022 нче уку елында әлеге дәреслекләр белән укытачакбыз.

Республика программасы нигезендә районыбызның Иске Суыксу мәктәбе белән М.Вахитов исемендәге гимназиягә татар теле кабинетлары өчен интерактив такталар кайтарылачак.

Бүгенге көндә район мәктәпләрендә 67 татар теле һәм әдәбияты укытучысы эшли. 14 укытучы югары, 46 укытучы I квалификацион категориягә ия. 7 укытучы үз вазифасына туры килә.

Дәреснең нәтиҗәлелеге күп очракта дөрес итеп куелган максаттан, әлеге максатка ирешү өчен методика яисә әсбап, җиһаз куллану һәм әлбәттә иң мөхиме – шул максатка ирешү өчен укытучының дөрес эшчәнлегеннән, алымыннан тора.

Татар телен укытуны камилләштерү буенча рустелле төркемнәрдә “Сәлам!” уку-укыту методик комплекты белән эшләүче укытучылар арта бара. Кыят, Толымбай, Күшке Тенәк, Алших һәм шәһәребезнең 4 мәктәпләрендә рустелле укучыларга татар телен өйрәнүне кызыклырак итү теләге белән язылган укыту әсбабы нигезендә шөгыльләнүче сыйныфлар бар. Әлеге укыту-методик комплекс буенча укучылар грамматик структураларны уен формасында өйрәнәләр. Шуңа күрә дәресләрдә укучылар күбрәк уйный, һәм балалар күбрәк сөйләшә, ягъни коммуникация ысулы бик нык үсеш алган. “Сәлам” уку-укыту методик комплекты— рустелле укучыларга татар телен өйрәнүне җиңеләйтә.

Балаларга туган (татар) телен өйрәтүдә икенче инновацион юнәлеш В.Н. Мещерякованың “Татар телем-илем теле” методикасы белән 2016 елдан башлап, Буа шәһәренең 5 нче гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Исхакова Л.Т. рус телле төркем укучыларына һәм Буа муниципаль районының Әлши урта мәктәбенең Туган тел һәм әдәбияты укытучысы Федорова Н. В. куллана. Бу методика туган телне үзләштерүнең табигый юлын кабатлый, балаларда дөрес тәрбия формалаштыра, уйнаганда, татар теленә хөрмәт уята һәм, иң мөһиме, сөйләшергә теләк тудыра. Бу технология, беренчедән, ата-аналарны өй эшен башкарудан азат итә,

икенчедән, балаларны татар телендә аралашуга этәрә, чөнки бу аралашу, нигездә, уен характерына ия. ата-аналар бу методикага югары бәя бирәләр.

Бүгенге көндә укытучыларга татар телендә белем һәм тәрбия бирүгә ярдәм итүче  сайтлар бар. Аларда  материаллар һәм татарча мультфильмнар урнаштырылган. Районыбызның татар теле укытучылары әлеге сайтлардан актив кулланып эшлиләр. Туган (татар) теле укытучылары тарафыннан 2020-2021 нче уку елында 4 сыйныфларның татар төркемнәре өчен дәрес эшкәртмәләре эшләнде. Алар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына урнаштырылды.

Узган уку елында дистанцион уку-укыту шартларында дәресләргә әзерләнү, дәресне тиешле югарылыкта үткәрү укытучыдан бик зур тырышлык таләп итте.

Татар мәктәбендә эшләүче укытучылар өчен “Мәгариф” журналы аеруча кадерле һәм кирәкле журнал. Бүген укытучы хезмәте дәрес бирү белән генә түгел, имтихан нәтиҗәләре, төрле конкурс-бәйгеләрдә җиңү белә дә бәяләнә. Бу яктан да журнал, беренчеләрдән булып, укытучыларга ярдәмгә ашыга. Татар телендә белем алган балаларга менә дигән мөмкинлек бу.

Укытучыларыбызның иҗади активлыгын арттыру максатыннан төрледән-төрле конкурслар да уздырып киләбез.

Туган  тел укытучылары “Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы” Бөтенроссия конкурсы, “Туган тел” Бөтенроссия мастер-класслар конкурсларының муниципаль этапларында актив катнашалар. 2 нче лицей укытучысы Сәлахетдинова Г.С. “Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы” конкурсының зона этабын уңышлы үтеп, республика этабында катнашты.

“Туган тел” мастер-класс бәйгесендә дә рус теле укытучысы Юсупова Алсу Расиховна белән  чуваш теле укытучысы Бахтинова Ольга Михайловна республика этабына уздылар.

Әлших урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Юнысова Л. Ә. «Россия халыкларының туган телләрен укытуның иң яхшы педагогик

практикалары конкурсы»ның читтән торып үткәрелгән этабында җиңүче булды һәм Мәскәү шәһәренә конкурсның турыдан-туры этабына чакырылды. Уңышлы чыгыш ясап, әлеге конкурсның финалисты булды.

Сәләтле балалар белән уку процессын сыйфатлы итү һәм укучыларда дәрескә кызыксындыру уяту максатыннан даими эш алып барыла.

Бу юнәлештә оештырылган эшнең нәтиҗәсе булып укучыларыбызның татар теленнән республика күләмендә уздырылган олимпиадаларда яулаган призлы урыннары тора.

Узган уку елында да татар теле һәм әдәбиятыннан 1 укучы җиңүче, 6 укучы призер, чуваш теленнән үткәрелгән Республика олимпиадаларында 2 укучыбыз призер булды. Шул ук укучылар Чебоксарда үткәрелгән Халыкара олимпиадада үзләренең көчләрен сынадылар.

Районда ел саен милли мәгарифне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрелә. Фәнни-гамәли конференцияләр, иҗади бәйгеләр, интеллектуаль уеннар үткәрү матур традициягә керде. Буа ягыннан чыккан якташ язучылар, галимнәр белән даими очрашулар оештырабыз, алар иҗатына багышланган конференцияләр үткәрәбез. Слайдларда сез аларны күрәсез.

| № | исеме | Үткәрү вакыты | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1. | “Шәҗәрәләр – нәсел агачы “- НПК | ноябрь | 120 |
| 2. | “Шәхесләргә бай милләт без...” -НПК | апрель | 100 |
| 3. | “Кояшлы ил” - НПК | март | 100 |
| 4. | Туган тел көне | февраль | 500 |
| 5. | Тукай көне | апрель | 500 |

“Сөмбелә", “Нәүрүз”, “Нардуган”, “Каз өмәсе”, “Татар кызы”, “Әбием сандыгы” кебек милли бәйрәмнәрдә балалар халкыбызның гореф-гадәтләре белән танышалар.

Татар телен өйрәтү буенча татар теле укытучылары өстәмә белем бирү хезмәтләре алып баралар. Әлки мәктәбендә “Матур сөйләм” түгәрәге, 5 нче номерлы гимназиядә “Цифрлы гасыр мәктәбе”, “Күңелле сәхнә”. Лицей-интернатта, 2 лицейда «Театр” түгәрәкләрендә укучылар театр сәнгатенә өйрәнәләр, артистлар тарафыннан оештырган мастер-классларында

катнашалар. Эшнең нәтиҗәсе дә күренә: 2019 нчы елда "Сәяр" республикакүләм конкурсында катнашып 5 нче гимназия укучылары лауреат исеменә лаек булдылар.

Җәй айларында укучылар мәгариф министрлыгы тарафыннан оештырылган җәйге лагерьларда ел саен бик теләп катнашалар. Алар «Дуслык», «Болгар - Туган тел», «Тартария», «Бүләк» аланнары. Әлеге аланнарда балалар туган телдә аралашу күнекмәләрен камилләштерәләр

15 нче гыйнвар көнне Буа шәһәренең Мәдәни үзәгендә "Милли мультfest" республика балалар кинофестиваленең муниципаль этабы үткәрелде. Фестивальның төп максаты – татар телен саклау, яшь тамашачылар мәдәниятен үстерү, балаларның, яшүсмерләрнең рухи, интеллектуаль һәм иҗади өлкәсен анимацион, кыска метражлы уен фильмнары һәм компьютер уеннары җитештерү ярдәмендә баетуга ярдәм итү. Әлеге кинофестивальнең муниципаль этабына балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрдән һәм мәктәп укучыларыннан 30 якын эш кабул ителде.

«Викимедиа РУ» коммерцияле булмаган оешмасы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия белән берлектә «Минем Татарстан» конкурсы игълан итте. Конкурсның төп максаты-республикабызның географиясе, мәдәнияте, тарихы һәм башка үзенчәлекләре турында яңа мәкаләләр җыю. Безнең районнан да конкурска 80 эш китте.

Хөрмәтле утырышта катнашучылар! Милли тәрбия бирүдә ата-аналарның роле зур урын алып тора.

Уку-укыту процессында –аналар белән дөрес эш алып бару да зур әһәмияткә ия. Алар белән тыгыз элемтәдә булып, дәресләргә чакыру, спектакльләр, концертлар күрсәтү, бергә төрле чаралар үткәрү татар теленә кызыксыну, мәхәббәт уята. Балаларының дәресләргә яратып йөрүләренә, татарча иркен сөйләшүләренә, дәрестә барысын да аңлауларына кайсы ата-

ана каршы булсын?! Гомумән, укучының һәрбер уңышын әти-әнисе белергә тиеш дип уйлыйм мин.

Буа муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә ата-аналарның туган телне өйрәнү турындагы фикерен ачыклау максатыннан сораштыру үткәрелде. 1213 респондент катнашты. Нәтиҗәдә, сораштырылучыларның күпчелеге (67,5 %) мәктәпләрдә туган телне укыту методикасыннан канәгать булуы ачыкланды. Ата-аналарның 79,5% ы мәктәпләрдә туган телне укыту сәгатьләре җитәрлек күләмдә алып барыла, дип саный. (Сәгатьләр саны татар мәктәпләрендә атнага 5 сәг, ә рус мәктәпләрендә 3 сәг. укытыла).

Әти-әниләрнең 58,2% ы туган (татар) телен белү киләчәктә һичшиксез кирәк булачак, дип ышана, шул ук вакытта 18,4% тискәре җавап биргән һәм 23,4% ата-аналар җавапсыз калган.

Сораштыру нәтиҗәләре буенча ата-аналарның туган (татар) телен укыту турында түбәндәге теләкләре алынды.

Мәсәлән:

1. Укучылар эшчәнлеген оештыруның кызыксындыручан формаларын кулланырга,

2. Рус төркемнәрендә татар телен укыту методикасын төрләндерергә.

3. Туган (татар) телен укыту мәсьәләләре буенча ата-аналарга аңлату эшләре алып барырга.

4. Рус телле балалар өчен өй эшенең күләмен киметергә

Милли белем һәм тәрбия бирү һәрвакыт мәгарифнең иң катлаулы юнәлешләренең берсе булып кала бирә. Хәл ителәсе мәсьәләләр дә күп.

- ✓ Федераль дәүләт стандартлары таләпләреннән чыгып, дәресләрне заманча проектлаштыру алымнарын барлык укытучыларның да практикада куллануына ирешү – төп бурычыбыз;

- ✓ Укучыларда коммуникатив - эшчәнлек, мәгълүмати, эчтәлекле, кызыклы итү, татар телен белүгә кызыксыну уяту, коммуникатив минимумны татар телендә сөйләм теленә өйрәтү нигезе буларак эшләү мөһим.
- ✓ мәгълүмати-коммуникацион технологияләр куллануны көчәйтергә һәм киңәйтергә, кирәкле дидактик материаллар булдырырга, олимпиада биремнәренең ачык банкларын булдырырга кирәк.
- ✓ Халыкара, республика олимпиадаларының нәтиҗәлелеген үстерү;
- ✓ Информацион технологияләрне тирәнтен өйрәнеп, укучылар белән уртак проектлар булдыру, район укучыларын татарча сайтлар ясауга тарту зарур! Блогерство, медиастудияләр видеороликлар тупланмасы булдыру;
- ✓ педагогларның һөнәри осталыгын күтәрү өчен альтернатив формалардан файдалану
- ✓ өзлексез һөнәри үсешне стимуллаштыручы механизмнарны булдыру өчен, укытучыларны, тәрбиячеләрне профессиональ конкурсларда, грантларда һәм олимпиадаларда актив катнаштыру.
- ✓ Татар теле һәм әдәбияты укытучыларын иң борчыганы – әдәбият дәреслекләре. Сүз дә юк, дәреслекләребез яңартылды, уңай якка үзгәрешләр бар. Яңа әдәбият дәреслекләрендә укучының яшь үзенчәлегенә туры килгән әсәрләр сайлауда, чорларга бүленешне бирүдә кимчелекләр бар. Хәзерге әдәбиятка урын аз бирелгән.
- ✓ Балалар бакчаларында билингваль төркемнәр белән беррәттән полилингваль төркемнәр оештырырга.
- ✓ Ата-аналарга балалар белән бергә Шаян ТВ каналында татар телендә тапшырулар трансляциясен карарга тәкъдим итәргә.

Минемчә, ана телен өйрәтү иң элек гаиләдән башланырга тиеш. Чөнки бала күп вакытын өйдә үткәрә, шуңа күрә телне, тәрбияне ул өйдә өйрәнеп ала. Һәр әти-әни баласы белән татарча сөйләшсен, Һәр гаиләдә

татар теле хөкем сөрсен иде. Аның матурлыгын, бөеклеген, көчен, мәгънәсен без балага һәрдаим күрсәтеп торырга тиеш. Чөнки халкыбызның гореф-гадәтләре, традиияләре, тарихы туган телебез белән бәйле.

Чыгышымны йомгаклап шуны әйтәсем килә Буа районы - милләтнең бөтен байлыгын саклаган төбәк. Хөрмәтле район, мәдәният һәм мәктәп җитәкчеләре! Халкыбыз бездән милли рухлы, милли үзаңы югары дәрәҗәдә булган телне, гореф-гадәтләрне саклый белүче, республика үсешенә зур өлеш кертердәй шәхесләр көтә. Милли мәгарифкә булган игътибарны тагын да көчәйтеп, аны үстерүдә бердәм эш алып барсак иде. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.